СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

31.10.2025 № 2/12

На №__________ от______________

# КАРАР

## «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суыксу авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советы карары үз көчен югалтуын тану хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы беренче өлеше 20 пункты, Тукай муниципаль районы уставы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2025 елның 29 сентябрендәге 01-09.22309 номерлы хатын, Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суыксу авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен раслау турында» 2025 елның 25 августындагы 1200/о номерлы боерыгын үтәү йөзеннән, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының 2023 елның 11 декабрендәге 40/4 номерлы карары белән (барлык үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суыксу авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен гамәлдән чыгарырга.
2. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суыксу авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының 2023 елның 11 декабрендәге 40/4 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суыксу авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының 2018 елның 20 августындагы 27/9 номерлы карары (23.04.2021 № 9/12 үзгәрешләр белән) үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталына урнаштырырга.
5. Әлеге карарны «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы
вазифаларын башкаручы,
Совет рәисе урынбасары

Р.И. Закиров